Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Ислəй авыл җирлеге Советы
карары

2025 елның 22 сентябре №1/5

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамəлгə кертү, ставкаларны, түлəү тəртибен билгелəү турында» 2016 елның 10 ноябрендəге 22/2 номерлы карарына үзгəрешлəр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һəм икенче өлешлəренə, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгəрешлəр кертү һəм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезлəмəлəренең үз көчлəрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендəге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендə, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының «Җир салымын гамəлгə кертү, ставкаларны, түлəү тəртибен билгелəү турында» 2016 елның 10 ноябрендəге 22/2 номерлы карарына түбəндəге үзгəрешлəрне кертергə:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасының өченче абзацында «(индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгəн) эшкуарлык эшчəнлегендə файдаланыла торган җир кишəрлеклəреннəн тыш)» сүзлəрен «, əлеге абзацта күрсəтелгəн индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгəн) эшкуарлык эшчəнлегендə файдаланыла торган җир кишəрлеклəреннəн һəм һəркайсының кадастр бəясе 300 миллион сумнан артып китə торган җир кишəрлеклəреннəн тыш» сүзлəренə алмаштырырга;

1.2. 3 пунктның тугызынчы абзацында «, һəркайсының кадастр бəясе 300 миллион сумнан артыграк булган əлеге абзацта күрсəтелгəн җир кишəрлеклəреннəн тыш.» сүзлəрен өстəргə.

2. Əлеге карарны «Татарстан Республикасының рəсми хокукый мəгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), авыл җирлегенең чиклəнмəгəн даирə затлары файдалана алырлык урыннарда урнашкан махсус мəгълүмат стендларына һəм Чистай муниципаль районының «Интернет» мəгълүмат-коммуникация челтəрендəге рəсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Əлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан, əмма рəсми басылып чыккан көненнəн кимендə бер ай узгач үз көченə керə.

Авыл җирлеге башлыгы К.А. Чернышева